**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4954**
**22.09.2022**

«2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасын раслау турында

Террорчылык һәм экстремизмны кисәтү системасын камилләштерү, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче халыкның террорчылык гамәлләреннән саклану дәрәҗәсен арттыру максатында, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетының «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13, «Мәктәпкәчә белем бирү» 07.01, «Гомуми белем бирү» 07.02, «Яшьләр сәясәте һәм балаларны сәламәтләндерү» 07.07 бүлекләрендә (бүлекчәләрендә) каралган акчалар хисабына 2023 елда – 14 441,56 мең сум, 2024 елда – 14 441,56 мең сум, 2025 елда – 14 441,56 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы Р.М. Мингалиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 22 сентябрендәге
4954 номерлы карарына
кушымта

«2023-2025 елларга
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү»
муниципаль программасы

1 бүлек. «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Экстремизм эшчәнлегенә каршы көрәш турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Террорчылыкка каршы тору чаралары турында» 2006 елның 15 февралендәге 116 номерлы Указы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге |
| Программаны үтәүчеләр | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе, Башкарма комитетның районнар хакимиятләре |
| Программаның максаты | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче халык тормышының саклану һәм тынычлык дәрәҗәсен күтәрү, Яр Чаллы шәһәрендә экстремизм һәм террорчылыкка каршы тору, ул күренешләрне профилактикалау һәм кисәтү нигезендә халыкның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау |
| Программаның бурычлары | 1. Идеология тәэсиренә дучар булган, шулай ук аның йогынтысына эләккән кешеләр белән профилактик эш өчен шартлар тудыру.<br>2. Яр Чаллы шәһәре халкында террорчылыкка каршы аңны формалаштыру.<br>3. Белем бирү оешмаларының һәм кеше күпләп җыела торган урыннарның террорчылыкка каршы сакланышын күтәрү буенча чаралар үткәрү |

<table>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары</td><td>2023-2025 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td>
<table>
<tr><th rowspan="2">Финанслау чыганаклары</th><th colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</th></tr>
<tr><th>2023 ел мең сум</th><th>2024 ел мең сум</th><th>2025 ел мең сум</th><th>Тормышка ашыру чорында барлыгы мең сум</th></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>14 441,56</td><td>14 441,56</td><td>14 441,56</td><td>43 324,68</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>14 441,56</td><td>14 441,56</td><td>14 441,56</td><td>43 324,68</td></tr>
</table>
</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td>Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә түбәндәгеләр күздә тотыла:<br>1) шәһәрнең кешеләр күпләп җыела торган объектларының, гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының террорчылыкка каршы сакланыш дәрәҗәсен күтәрү;<br>2) халыкта толерант тәртип формалаштыруны дәвам итү, интернационализм, татулык, милли һәм дини түземлелек культурасын тарату</td></tr>
<tr><td>Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td>Программа үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге гамәлгә ашыра</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

«2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасы (алга таба – программа) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге потенциаль куркыныч объектларның, кешеләр күпләп җыела торган урыннарның һәм яшәешне тәэмин итү объектларының террорчылыкка каршы сакланышын тәэмин итүгә юнәлдерелгән террорчылыкны профилактикалау системасының гомуми торышын исәпкә алып эшләнде.

Бүгенге көндә Яр Чаллы шәһәре – Татарстан Республикасының күп милләтле һәм күп динле муниципаль берәмлеге. Шәһәр территориясендә 37 дини оешма һәм төркем эшли, шуларның 18 – мөселман, 11 – православие, 1 – рус православиесе иске йолалар җәмгыяте, 1 – яһүд дини оешмасы, 6 – протестант. Дини һәм иҗтимагый оешмалар белән уңышлы хезмәттәшлек механизмы җайга салынган. Иҗтимагый-сәяси, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы, тулаем алганда, төрле социаль төркем, милләт һәм дин вәкилләренең тотрыклылыгы, дустанә, конструктив үзара эшчәнлеге һәм хезмәттәшлеге белән характерлана.

Үз илебезнең дә, чит ил экстремизм үзәкләре дә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә потенциаль омтылыш объекты буларак карыйлар. Ситуация шәһәрдә критик мөһим объектларның күп санда булуы белән катлаулана. Тискәре процессларны анализлау, милли, миграция, яшьләр, мәгълүмати сәясәт, мәгариф һәм җәмәгать тәртибен саклау өлкәләрендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалауның максатчан программа методын кабул итү һәм комплекслы якын килү зарурлыгы турында раслый.

Программа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өчен ачык документ булып тора.

## 3 бүлек. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаның төп максаты булып террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтү системасын камилләштерү, халыкны, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан белем бирү оешмаларының мөмкин булган террорчылык гамәлләреннән саклану дәрәҗәсен күтәрү тора.

Программаның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) халык белән террорчылык һәм экстремизм эшчәнлеген кисәтүгә юнәлдерелгән тәрбия, пропаганда эшләре үткәрү;

2) шәһәрнең белем бирү оешмаларының террорчылыкка каршы сакланышын күтәрү чараларын тәэмин итү.

## 4 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

Программаны тормышка ашыруның арадаш һәм ахыргы нәтиҗәләрен бәяләү өчен нәтиҗәлелекне бәяләүнең түбәндәге индикаторлары файдаланыла:

| Т/б | Индикаторларның исеме | Исәпләү методикасы | Чыганаклар |
|---|---|---|---|
| 1. | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә кылынган террорчылык актлары саны | N – сан | ТР буенча РФ ФКХИ Яр Чаллы шәһәрендәге хезмәте; Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе |
| 2. | Төзек видеокүзәтү системалары, хәвеф сигнализациясе төймәләре булган муниципаль оешмалар өлеше | Ди = Кнм о/ Кмо х 100%, монда<br>Ди – төзек саклау системалары булган муниципаль оешмалар өлеше;<br>Кмо – саклау системасы булган муниципаль оешмалар саны;<br>Кнмо – төзек саклау системалары булган муниципаль оешмалар саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе |

## 5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

2023-2025 елларга программаны финанслау күләме 43 324,68 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча: 2023 ел – 14 441,56 мең сум, 2024 ел – 14 441,56 мең сум, 2025 ел – 14 441,56 мең сум.

## 6 бүлек. Программаны тормышка ашыру сроклары. Программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту системасы

Программа 2023-2025 еллар дәвамында гамәлдә.

Программа үтәлешен гомуми контрольдә тотуны Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге гамәлгә ашыра.

## 7 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге террорчылык актлары янаулары дәрәҗәсен киметү нигезендә бәяләнә. Социаль нәтиҗәлелек ел саен үткәрү планлаштырыла торган социологик тикшеренүләр мәгълүматлары буенча бәяләнә.

Программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

1) шәһәрнең кешеләр күпләп җыела торган объектларының, гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының террорчылыкка каршы сакланыш дәрәҗәсен күтәрергә;

2) халыкта толерант тәртип формалаштыруны дәвам итәргә, интернационализм, татулык, милли һәм дини түземлелек культурасын таратырга.

8 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чараларын финанслау

| Т/б | Төп чараларның исеме | Башкаручы | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | база | 2023 | 2024 | 2025 | 2023 | 2024 | 2025 |
| Максат: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче халык тормышының сакланыш һәм тынычлык дәрәҗәсен күтәрү, Яр Чаллы шәһәрендә экстремизм һәм террорчылыкка каршы тору, ул күренешләрне профилактикалау һәм кисәтү нигезендә халыкның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау | | | | | | | | | | | |
| 1 бурыч. Идеология тәэсиренә дучар булган, шулай ук аның йогынтысына эләккән кешеләр белән профилактик эш өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | | | |
| 1. | «Аерым игътибар» (куркыныч) категориясендәге затлар белән эшләү буенча муниципаль эшче төркем утырышларын үткәрү | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча) | квартал саен | муниципаль эшче төркем утырышлары саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |
| 2. | «Аерым игътибар» (куркыныч) категориясендәге затлар белән адреслы профилактик чараларда катнашу өчен коммерцияле булмаган (шул исәптән дини) оешмаларны һәм җәмәгать активистларын стимуллаштыру чараларын тормышка ашыру | Коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча), Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге | 2023-2025 | Җәмәгать активистларын җәлеп итеп, профилактик эшкә җәлеп ителгән «аерым игътибар» (куркыныч) категориясендәге затлар өлеше, % | - | - | 20 | 30 | финанслау таләп ителми | | |
| 3. | «Аерым игътибар» (куркыныч) категориясендәге затлар белән эшләүдә катнашучы вазифаи затларны һәм | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, Башкарма комитет мәгълүмати сәясәт | 2023-2025 | белем алган, квалификацияле белгечләр саны, берәмлек | - | - | 2 | 2 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | җәмәгать активистларын әзерләү, хәлне диагностикалау, психологик һәм психотерапевтик ярдәм күрсәтү өчен квалификацияле белгечләрне җәлеп итү | һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге, коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча) | | | | | | | |
| 4. | Яшьләр белән эшләү идарәсе, спорт оешмалары белгечләренең, яшьләр җәмәгать активистларының «аерым игътибар» (куркыныч) категориясендәге затларга социаль характердагы өзлексез ярдәм чараларын тормышка ашыруда катнашуы | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча) | ел дәвамында | күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтелгән «аерым игътибар» (куркыныч) категориясендәге затлар өлеше, берәмлек | - | - | 5 | 10 | финанслау таләп ителми |
| 5. | Функциональ регламент белән беркетелгән белем бирү оешмаларының вазыйфаи затларының «аерым игътибар» категориясендәге затлар белән алдан адреслы эш үткәрүдә катнашуы | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча) | даими | «аерым игътибар» (куркыныч) категориясендәге затлар (яки аларның балалары) белем ала торган уку сыйныфлары | - | - | 70 | 80 | финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | белән төркемле коррекция чаралары (тренинглар, семинарлар) өлеше, берәмлек | | | | | |
| 6. | Адреслы профилактик эштә катнашучы белгечләрнең тармакара һөнәри осталык семинарын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ, коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча) | ел саен | семинарлар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |
| 7. | Мәгариф һәм яшьләр сәясәте өлкәсенә социаль педагогларны җәлеп итү өчен яшьләр мохитендә һәм белем бирү өлкәсендә һөнәри юнәлеш бирү эшен оештыру һәм үткәрү, тиешле белем алуда һәм алга таба Яр Чаллы шәһәрендә белгечлек буенча эшкә урнашуда мәгълүмати ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча) | даими | чаралар саны, берәмлек | - | - | 12 | 12 | финанслау таләп ителми |
| 8. | Террорчылык идеологиясен җитди кабул итмәүгә һәм массакүләм мәгълүмат | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, | 2023-2025 | мондый аңлатмалар белән чыгыш | - | - | 5 | 5 | финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | чараларында, социаль челтәрләрдә, гавами чараларда традицион Россия рухи-әхлакый кыйммәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән чыгышларга аерым игътибар (куркыныч) категориядәге затларны җәлеп итү эшен оештыру | Башкарма комитет мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе, коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча) | | ясаган «аерым игътибар» (куркыныч) категориясендәге затларның өлеше, % | | | | | |
| 9. | Системалы хезмәт һәм уку процессларына җәлеп ителмәгән яшьләрне, шулай ук формаль булмаган яшьләр формированиеләре вәкилләрен иҗтимагый әһәмиятле социаль проектларны һәм программаларны тормышка ашыруга җәлеп итү буенча чараларны оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитет мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге, коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча) | ел саен | чаралар саны, берәмлек | - | - | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |
| 10. | «Интернет» челтәрендәге деструктив берләшмәләрдә муниципаль берәмлектә яшәүчеләрнең активлыгына мониторинг үткәрү | коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча) | ел саен | мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмати белешмәләр саны, берәмлек | 12 | 12 | 12 | 12 | финанслау таләп ителми |

<table>
<tr><td rowspan="2">11.</td><td rowspan="2">Аерым затка яки затлар төркемнәренә карата нәфрәт һәм дошманлык, шулай ук раса, милләт һәм дингә мөнәсәбәт билгеләре буенча кешелекнең абруен төшерү билгеләренә ия булган мәгълүмати материалларга психологик-лингвистик экспертизалар һәм тикшеренүләр үткәрүне оештыру</td><td rowspan="2">Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге</td><td rowspan="2">ел саен</td><td rowspan="2">бирелгән экспертизалар үтәлеше, %</td><td rowspan="2">100</td><td rowspan="2">100</td><td rowspan="2">100</td><td rowspan="2">100</td><td colspan="3">Муниципаль бюджет</td></tr>
<tr><td>500,0</td><td>500,0</td><td>500,0</td></tr>
<tr><td>12.</td><td>Татарстан Республикасы өчен традицион ислам формаларын танытучы дини лидерларны әзерләү өчен, дини оешмалар җитәкчелеге белән берлектә Россиянең алдынгы теология уку йортларына (Болгар ислам академиясенә) кандидатлар сайлап алу һәм аларны җибәрүне оештыру</td><td>Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе</td><td>2023-2025</td><td>җибәрелгән кандидатлар саны, кеше</td><td>-</td><td>-</td><td>1</td><td>1</td><td colspan="3">финанслау таләп ителми</td></tr>
<tr><td colspan="12">2 бурыч. Яр Чаллы шәһәре халкында терророчылыкка каршы аңны формалаштыру</td></tr>
<tr><td>13.</td><td>Мәгълүмат-пропаганда төркеме эшчәнлеген тәэмин итү</td><td>Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча)</td><td>2023-2025</td><td>эшче төркем утырышлары саны, берәмлек</td><td>-</td><td>-</td><td>4</td><td>4</td><td colspan="3">финанслау таләп ителми</td></tr>
<tr><td>14.</td><td>Терророчылыкны, экстремизмны</td><td>Башкарма комитетның халык</td><td>2023-2025 еллар</td><td>Буклетлар әзерләү, данә</td><td>300</td><td>300</td><td>300</td><td>300</td><td colspan="3">Муниципаль бюджет</td></tr>
</table>

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | профилактикалау буенча буклетлар, плакатлар эшләү, белешмәлекләр һәм календарьлар тарату | иминлеген тәэмин итү бүлеге | | Плакатлар әзерләү, данә | 300 | 300 | 300 | 300 | 32,0 | 32,0 | 32,0 |
| | | | | Белешмәлекләр әзерләү, данә | 300 | 300 | 300 | 300 | | | |
| | | | | Өй рәвешендәге календарьлар эшләү, данә | 300 | 300 | 300 | 300 | | | |
| 15. | Яшьләр арасында экстремизмны профилактикалау, позитив тормыш кыйммәтләре формалаштыру буенча мәгълүмати материаллар бастырып чыгару | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | ел саен | буклетлар, данә | 800 | 800 | 800 | 800 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| 16. | Халык белән мәгълүмат-аңлату эшләре алып бару өчен, квалификацияле лектор-пропагандистларны җәлеп итү | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча) | 2023-2025 | җәлеп ителгән лекторлар тарафыннан үткәрелгән лекцияләр/чыгышлар саны, берәмлек | - | - | 2 | 2 | финанслау таләп ителми | | |
| 17. | Халык белән мәгълүмати-аңлату эшләре алып бару өчен лектор-пропагандистларның муниципаль активын әзерләү | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, коррупциягә каршы тору буенча | 2023-2025 | муниципаль берәмлектә яшәүчеләр арасыннан укытылган, квалификацияле лекторлар саны, кеше | - | - | 2 | 2 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хаким ярдәмчесе (килешү буенча) | | | | | | | |
| 18. | Террорчылыкка каршы көрәштә бердәмлек көненә багышланган мәдәни һәм спорт чаралары үткәрү (3 сентябрь) | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |
| 19. | Экстремизм һәм террорчылыкны профилактикалау буенча «Экстремизмга – Юк» айлыгы үткәрү | Башкарма комитетның район хакимиятләре, Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге, коррупциягә каршы тору буенча Хаким ярдәмчесе (килешү буенча) | сентябрь ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |
| 20. | Уяулыкны саклау һәм террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу мәсьәләләре буенча территориаль иҗтимагый үзидарә рәисләре белән киңәшмәләр үткәрү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | ай саен | чаралар саны, берәмлек | 12 | 12 | 12 | 12 | финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 21. | Муниципаль берәмлекнең «Интернет» челтәрендә социаль челтәрләрнең муниципаль сегментында, башка мәгълүмат ресурсларында террорчылыкка каршы эчтәлекле мәгълүмат, шул исәптән видеороликлар эшләү (туплау) һәм урнаштыру | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе, Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | 2023-2025 | урнаштырылган материаллар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |
| 22. | Массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми дини конфессияләр вәкилләренең террорчылыкка каршы тору эшендә гражданнарны берләштерүгә юнәлдерелгән тематик вәгазьләрен бастырып чыгару | Башкарма комитет мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге | ел саен | басылып чыккан материаллар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |
| 23. | Милли диаспораларны җәлеп итү:<br>- террорчылык һәм экстремизм эшчәнлеген кисәтүгә юнәлдерелгән эш үткәрүгә;<br>- этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне ныгытуга юнәлтелгән уртак чаралар оештыруга һәм үткәрүгә | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» МАМУ | квартал саен | чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми |
| 24. | Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау темаларына яшьләр арасында кейс-чемпионатлар, квестлар, түгәрәк өстәлләр, | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | очрашулар, фестивальләр, конкурслар һәм акцияләр оештыру һәм үткәрү | | | | | | | | | | |
| 25. | Террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору проблемалары буенча Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары студентлары арасында тикшеренү эшләре һәм проектлар (акцияләр һәм чаралар) конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Нур» яшьләр үзәге» МАУ | 2023-2025 еллар | бүләкләнүчеләр саны (бүләкләрне финанслау), кеше | 6 | 6 | 6 | 6 | Муниципальный бюджет | | |
| | | | | | | | | | 18,0 | 18,0 | 18,0 |
| 26. | «Без халыклар дуслыгы яклы! Без көч куллануга каршы!» иң яхшы иҗади эш конкурсы үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, «2 нче балалар сәнгать мәктәбе» МАӨББУ | ел дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 27. | Тәрбия, үзара аңлашу, милләтара бердәмлек, балаларның медиа иминлеге мәсьәләләрендә белем дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән «Ата-аналар өчен университет» форматында дәресләр оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | ел дәвамында | профилактик дәресләр алып барган ата-аналарның гаиләләрнең гомуми санындагы өлеше, % | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28. | Балалар һәм яшьләр, ата-аналар һәм яшьләр белән эшләүче белгечләр өчен экстремизмны профилактикалау, этникара һәм конфессияара татулык, толерантлык формалаштыру буенча чаралар үткәрү | «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | ел саен | чаралар саны, берәмлек | 10 | 10 | 10 | 10 | финанслау таләп ителми |
| 29. | Белем бирү оешмаларында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге закон нигезләрен аңлату буенча дәресләр үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | уку елы дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 2 | 2 | 2 | 2 | финанслау таләп ителми |
| 30. | Белем бирү оешмаларында этникара һәм динара килешү шартларында яшәү ихтыяҗларын формалаштыру һәм ныгыту максатында укучыларның актив катнашу формаларына юнәлдерелгән чаралар (рольле уеннар, конкурслар һ.б.) оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | уку елы дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 2 | 2 | 2 | 2 | финанслау таләп ителми |
| 31. | Белем бирү оешмаларында укучылар арасында укучыларда милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрдә толерантлыкны үстерүгә юнәлдерелгән сыйныф сәгатьләре үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | уку елы дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 2 | 2 | 2 | 2 | финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 32. | Республика һәм федераль дәрәҗәдә оештырылган, террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләренә багышланган яшьләр форумнарында катнашу | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «ФОРПОСТ» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» МБУ | ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |
| 33. | Яшүсмерләр һәм яшьләр мохитендә экстремизмны профилактикалау һәм толерантлык формалаштыру өлкәсендә эш оештыру буенча яшьләр сәясәте белгечләренең методик берләшмәсе эше кысаларында тематик семинар үткәрүне тәэмин итү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | ел саен | чаралар саны, берәмлек | 3 | 3 | 3 | 3 | финанслау таләп ителми |
| 34. | Югары һәм һөнәри белем бирү оешмаларының педагог-психологларын җәлеп итеп, этникара һәм конфессияара килешүнең формалашу дәрәҗәсен билгеләүгә юнәлдерелгән сораштыру үткәрүне тәэмин итү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | уку елы дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 бурыч. Шәһәрнең белем бирү оешмаларының һәм кеше күпләп җыела торган урыннарның террорчылыкка каршы сакланышын күтәрү чараларын үткәрү | | | | | | | | | | | |
| 35. | Гомуми белем бирү оешмаларында хәвеф сигнализациясе төймәсен карап тоту һәм ведомстводан тыш саклау | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | ел саен | гомуми белем бирү оешмаларының төзек видеокүзәтү системалары һәм хәвеф сигнализациясе төймәләре белән тәэмин ителеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 4 417,17 | 4 417,17 | 4 417,17 |
| 36. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында хәвеф сигнализациясе төймәсен карап тоту һәм ведомстводан тыш саклау | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | ел саен | мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының төзек видеокүзәтү системалары һәм хәвеф сигнализациясе төймәләре белән тәэмин ителеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 9454,39 | 9454,39 | 9454,39 |
| 37. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләр күпләп җыела торган урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы сакланышына карата таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | кирәк булган саен | чаралар саны, берәмлек | | | | | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (территорияләрнең) куркынычсызлык паспортлары формаларын раслау турында» 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карары (алга таба – 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карар) нигезендә кешеләр күпләп җыела торган урыннар реестрын актуальләштерү | | | | | | | | | | |
| 38. | 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карар нигезендә, комиссия тарафыннан, кешеләр күпләп җыела торган урыннарны террорчылык актларын кисәтү һәм профилактикалау, террорчылыкка каршы саклану предметына тикшерү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | кирәк булган саен | чаралар саны, берәмлек (кирәк булганда) | | | | | финанслау таләп ителми | | |
| барлыгы: | | | | | | | | | 14 441,56 | 14 441,56 | 14 441,56 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева